# ПРОГРАММА
## сотрудничества в торгово-экономической и культурно-гуманитарной областях между Республикой Татарстан (Российская Федерация) и Туркменистаном на 2012-2014 годы

Настоящая Программа сотрудничества в торгово-экономической и культурно-гуманитарной областях между Республикой Татарстан (Российская Федерация) и Туркменистаном на 2012-2014 годы (далее – Программа) разработана на основе положений Соглашения между Правительством Республики Татарстан (Российская Федерация) и Правительством Туркменистана о торгово-экономическом, научно-техническом и культурном сотрудничестве, подписанного 28 июня 2008 года в г. Казани, и служит основой для развития татарстано-туркменских отношений на указанный период.

## 1. Основные цели и задачи Программы

Настоящая Программа разработана в целях осуществления Республикой Татарстан и Туркменистаном (далее – Стороны) на долгосрочной основе комплекса мер по оказанию государственной поддержки развитию экономических и культурных отношений между Республикой Татарстан и Туркменистаном, обеспечению тесного сотрудничества ведущих отраслей их экономики, укреплению благосостояния их народов и удовлетворению духовно-культурных потребностей.

В процессе реализации настоящей Программы предстоит решить следующие задачи:

- реализация совместных проектов на приоритетных направлениях экономического, социального и культурного сотрудничества, взаимная поддержка национальных и иностранных инвесторов на территориях Республики Татарстан и Туркменистана;
- создание совместных предприятий, торговых домов, представительств и других структур различного профиля;
- обмен открытой информацией торгово-экономического и научно-технического характера, представляющей взаимный интерес;
- реализация мер по укреплению и развитию гуманитарного сотрудничества, взаимодействие в социальной, культурной и иных сферах;
- использование и развитие международных транспортных коммуникаций и связи;
- развитие и внедрение передовых информационных технологий;
- создание благоприятных условий для субъектов экономической

деятельности Республики Татарстан и Туркменистана в сфере спорта и туризма (далее - субъектов экономической деятельности).

## 2. Основные направления развития экономического сотрудничества

Программой намечена реализация комплекса мер по дальнейшему развитию взаимовыгодного сотрудничества.

К наиболее перспективным направлениям двустороннего экономического сотрудничества Стороны относят:

- проведение национальных и международных выставок, ярмарок, семинаров, конференций и мероприятий по информационному обмену и установлению деловых контактов между субъектами экономической деятельности;

- обмен информацией о мерах по созданию стимулов для развития производственной деятельности, увеличению притока инвестиций, применению передовых технологий, повышению качества выпускаемой продукции;

- осуществление поставок авиационной, автомобильной и другой техники и оборудования;

- обмен опытом по внедрению научных достижений и разработок в различных отраслях материального производства;

- организация взаимных поставок текстильных изделий, ковров и ковровой продукции;

- развитие инфраструктуры и базы спорта и туризма.

В целях дальнейшего развития экономик Республики Татарстан (Российская Федерация) и Туркменистана Стороны будут способствовать повышению конкурентоспособности продукции, производимой их предприятиями, созданию благоприятных условий для продвижения товаров на рынках третьих государств, развитию экспортного потенциала.

В рамках обеспечения реализации намеченной Программы Стороны совместно осуществят:

- привлечение к участию в соответствующих компонентах Программы заинтересованных министерств и ведомств, предприятий и организаций, а также предпринимательских структур Республики Татарстан и Туркменистана;

- проведение инвестиционных форумов и встреч с участием представителей соответствующих министерств и ведомств, предприятий, организаций и компаний, предпринимательских и других заинтересованных структур, способствующих вовлечению потенциальных инвесторов в развитие экономического потенциала Республики Татарстан и Туркменистана.

## 3. Сотрудничество в гуманитарной сфере

Реализация Программы предполагает консолидацию усилий по обеспечению дальнейшего развития сотрудничества в области здравоохранения, образования, науки, культуры и искусства, спорта и туризма.

Стороны признают приоритетными следующие основные направления развития сотрудничества в гуманитарной области:

- образовательная деятельность, включая подготовку и повышение квалификации кадров на взаимосогласованных условиях;

- обмен научной информацией, публикациями и другими научными материалами, представляющими взаимный интерес, организация визитов деятелей науки, содействие взаимному обмену научными идеями;

- обмен информацией о проводимых конференциях и других мероприятиях в области медицины и медицинской науки.

Стороны содействуют развитию прямых партнерских связей в области образования между учебными заведениями, оказывают содействие в организации обучения и научных стажировок в учреждениях высшего профессионального образования Сторон.

В области научного сотрудничества Стороны поощряют совместные научные исследования и обмен материалами, представляющими взаимный интерес, оказывают содействие научным организациям Республики Татарстан и Туркменистана в привлечении ученых к участию в публикациях научных исследований.

В области культуры Стороны способствуют контактам между творческими организациями Республики Татарстан и Туркменистана, содействуют организации визитов творческих коллективов и деятелей культуры.

Стороны способствуют развитию взаимовыгодной туристской деятельности, поддерживают установление и развитие деловых связей между экономическими субъектами, осуществляющими деятельность в сфере туризма и экскурсионную деятельность.

Стороны поощряют сотрудничество между спортивными организациями, обществами, федерациями, командами и тренерами из Республики Татарстан и Туркменистана и содействуют установлению контактов специалистов по различным видам спорта.

## 4. Контроль за реализацией Программы

Контроль за выполнением настоящей Программы возлагается на Совместную татарстано-туркменскую рабочую группу по торгово-экономическому, научно-техническому и культурному сотрудничеству.

## 5. Заключительные положения

В соответствии с настоящей Программой министерства и ведомства Республики Татарстан и Туркменистана разработают и утвердят конкретные планы действий.

Настоящая Программа вступает в силу с даты её подписания Сторонами и действует до 31 декабря 2014 года.

Совершено «16» мая 2012 года в г.Казани в двух экземплярах, имеющих одинаковую юридическую силу, каждый на русском, татарском и туркменском языках.

| | |
|---|---|
| **За Правительство Республики Татарстан (Российская Федерация)** | **За Правительство Туркменистана** |
| **Президент Республики Татарстан** | **Президент Туркменистана** |
| **Р.Н.Минниханов** | **Г.М.Бердымухамедов** |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ * ПРЕЗИДЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

16.05.2012
№ 10

**2012–2014 елларга**
**Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе)**
**һәм Төрекмәнстан арасында сәүдә-икътисадый һәм**
**мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлек**
**ПРОГРАММАСЫ**

2012–2014 елларга Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) һәм Төрекмәнстан арасында сәүдә-икътисадый һәм мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлекнең әлеге программасы (алга таба – Программа) 2008 елның 28 июнендә Казан шәһәрендә кул куелган Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) Хөкүмәте һәм Төрекмәнстан Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешү нигезләмәләренә таянып эшләнде һәм күрсәтелгән чорга Татарстан-Төрекмәнстан мөнәсәбәтләрен үстерү өчен нигез булып хезмәт итә.

## 1. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Әлеге Программа Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан (алга таба – Яклар) тарафыннан Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан арасында икътисадый һәм мәдәни мөнәсәбәтләрне үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү, аларның әйдәп баручы икътисад тармакларында тыгыз хезмәттәшлекне тәэмин итү, халыкларының тормыш хәле тотрыклылыгын арттыру һәм аларның рухи-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча озак вакытка исәпләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру максатларында эшләнде.

Программаны гамәлгә ашыру барышында түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан территорияләрендә икътисадый, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлекнең өстенлекле юнәлешләрендә уртак проектларны гамәлгә ашыру, милли һәм чит ил инвесторларына үзара булышлык күрсәтү;
- уртак предприятиеләр, сәүдә йортлары, вәкиллекләр һәм төрле башка структуралар булдыру;
- үзара кызыксыну тудыручы сәүдә-икътисадый һәм фәнни-техник характердагы ачык мәгълүмат алмашу;
- гуманитар хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, социаль, мәдәни һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек;
- халыкара транспорт коммуникацияләреннән һәм элемтәдән файдалану һәм аларны үстерү;
- алдынгы мәгълүмати технологияләрне үстерү, кертү;

- спорт һәм туризм өлкәсендә Татарстан Республикасының һәм Төрекмәнстанның икътисадый эшчәнлеге субъектлары (алга таба – икътисадый эшчәнлек субъектлары) өчен уңай шартлар тудыру.

## 2. Икътисадый хезмәттәшлекне үстерүнең төп юнәлешләре

Программа үзара файдалы хезмәттәшлекне тагын да үстерү буенча комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны билгели.

Ике яклы икътисадый хезмәттәшлекнең иң перспективалы юнәлешләренә Яклар түбәндәгеләрне кертә:

- милли һәм халыкара күргәзмәләр, ярминкәләр, семинарлар уздыру, мәгълүмат алмашу һәм икътисадый эшчәнлек субъектлары арасында эшлекле багланышлар урнаштыру буенча конференцияләр һәм чаралар үткәрү;
- производство эшчәнлеген үстерү өчен стимуллар булдыру, инвестицияләр агымын көчәйтү, алдынгы технологияләр куллану, эшләп чыгарылучы продукциянең сыйфатын яхшырту буенча мәгълүмат алмашу;
- авиация, автомобиль техникасы, башка техника һәм җиһазлар куюны тормышка ашыру;
- матди җитештерүнең төрле өлкәләрендә фәнни казанышларны һәм эшләнмәләрне кулланышка кертү буенча тәҗрибә уртаклашу;
- текстиль эшләнмәләр, келәмнәр һәм келәм продукциясен үзара кайтаруны оештыру;
- спорт һәм туризм инфраструктурасын һәм матди базасын үстерү.

Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) һәм Төрекмәнстан икътисадларын тагын да үстерү максатларында Яклар үз предприятиеләрендә җитештергән продукциянең конкуренциягә сәләтен күтәрүгә, өченче дәүләтләр базарларына товарлар җибәрү өчен уңай шартлар булдыруга, экспорт потенциалын үстерүгә булышлык итәчәк.

Билгеләнгән программаны гамәлгә ашыруны тәэмин итү кысаларында Яклар бергәләшеп түбәндәгеләрне тормышка ашырачак:

- Программаның тиешле компонентларында катнашуга Татарстан Республикасының һәм Төрекмәнстанның кызыксынган министрлыкларын һәм ведомстволарын, предприятие һәм оешмаларын, шулай ук эшкуарлык структураларын җәлеп итү;
- Татарстан Республикасының һәм Төрекмәнстанның икътисадый мөмкинлекләрен үстерүгә потенциаль инвесторларны җәлеп итүгә булышучы тиешле министрлыклар һәм ведомстволар, предприятие, оешмалар һәм компанияләр вәкилләре, эшкуарлык һәм башка кызыксынган структуралар катнашында инвестиция форумнары һәм очрашулары үткәрү.

## 3. Гуманитар өлкәдә хезмәттәшлек

Программаны гамәлгә ашыру сәламәтлек саклау, мәгариф, фән, мәдәният һәм сәнгать, спорт һәм туризм өлкәләрендә хезмәттәшлекне тагын да үстерүне тәэмин итү буенча көчләрне берләштерүне күздә тота.

Яклар гуманитар өлкәдә хезмәттәшлекне үстерүнең түбәндәге төп юнәлешләрен өстенлекле дип таный:

- үзара килештерелгән шартларда кадрлар әзерләүне һәм аларның квалификациясен күтәрүне дә кертеп, мәгариф эшчәнлеге;
- үзара кызыксыну тудыручы фәнни мәгълүмат, публикацияләр һәм башка фәнни материаллар алмашу, фән эшлеклеләренең сәфәрләрен оештыру, фәнни идеяләрне үзара алмашуга ярдәм итү;
- медицина һәм медицина фәне өлкәсендә уздырылучы конференцияләр һәм башка чаралар турында мәгълүмат алмашу.

Яклар мәгариф өлкәсендә уку йортлары арасында турыдан-туры партнерлык элемтәләрен үстерүгә ярдәм итә, югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укытуны һәм фәнни стажировкаларны оештыруга булышлык күрсәтә.

Фәнни хезмәттәшлек өлкәсендә Яклар уртак фәнни тикшеренүләрне һәм үзара кызыксыну тудыручы материал алмашуны хуплый, Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан фәнни оешмаларына фәнни тикшеренүләрне бастырып чыгаруда катнашуга галимнәрне җәлеп итүдә булыша.

Мәдәният өлкәсендә Яклар Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан иҗади оешмалары арасында багланышларны хуплый, иҗади коллективлар һәм мәдәният эшлеклеләре сәфәрләрен оештыруга булышлык итә.

Яклар үзара файдалы туристлык эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итә, туризм өлкәсендә һәм экскурсион эшчәнлекне тормышка ашыручы икътисадый субъектлар арасында эшлекле элемтәләр урнаштыруга һәм аларны үстерүгә ярдәм итә.

Яклар Татарстан Республикасыннан һәм Төрекмәнстаннан спорт оешмалары, җәмгыятьләре, федерацияләре, командалары һәм тренерлары арасында хезмәттәшлекне хуплый һәм спорт төрләре буенча белгечләрнең багланыш урнаштыруына булышлык итә.

## 4. Программаны гамәлгә ашыруга контроль

Әлеге Программаның үтәлешенә контроль Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек буенча уртак Татарстан-Төрекмәнстан эш төркеменә йөкләнә.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

Әлеге Программа нигезендә Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан министрлыклары һәм ведомстволары гамәлләренең анык планнарын эшләячәк һәм раслаячак.

Әлеге Программа аңа кул куелган вакыттан үз көченә керә һәм 2014 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

2012 елның «16» маенда Казан шәһәрендә бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәркайсы татар, рус һәм төрекмән телләрендә башкарылды.

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) Хөкүмәте өчен** | **Төрекмәнстан Хөкүмәте өчен** |
| **Татарстан Республикасы Президенты** | **Төрекмәнстан Президенты** |
| **Р.Н. Миннеханов** | **Г.М.Бирдемөхәммәдов** |

16.05.2012
№ 10